КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1043

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрүне оештыру турында» 2013 ел, 22 июль, 512 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрүне оештыру турында» 2013 ел, 22 июль, 512 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 декабрь, 985 нче; 2014 ел, 7 июнь, 383 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 849 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрүне оештыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына:

түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә формасын;

Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрү өчен медицина оешмалары исемлеген;

медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрү нәтиҗәләре буенча исәпләр реестрларын «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә кертү тәртибен;

ел саен Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы гаризасы нигезендә Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләрен үткәрү өчен акчага ихтыяҗ формалаштыруны һәм норматив чыгымнар һәм хезмәт күрсәтүләр күләмнәре турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертүне тәэмин итәргә.»;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгына ел саен, медицина тикшерүләрен үтәргә тиешле хезмәткәрләр санын күрсәтеп, балалар савыктыру оешмалары (дәүләт, муниципаль) исемлеген формалаштыруны һәм агымдагы елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына кертүне тәэмин итәргә.»;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрүне оештыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә медицина тикшерүләре үткәрүне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары, хисап аеннан соң килүче айның 5 еннән дә соңга калмыйча, алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрү нәтиҗәләре буенча исәпләр реестрларын Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе белән килештерелгән форматларда һәм структураларда сакланылган ысул белән электрон рәвештә «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә кертә.

Нигезле сәбәбе булмыйча, күрсәтелгән вакытны бозып кертелгән исәпләр реестрлары түләү өчен кабул ителми.

«Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрү нәтиҗәләре буенча исәпләр реестрларына медицина-икътисад тикшерүен үткәрә һәм, хисап аеннан соң өчен килүче айның 10 сыннан да соңга калмыйча, түләнергә тиешле исәпләр реестрлары турындагы мәгълүматны Диспетчерлар үзәгенә кертә.»;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының балалар савыктыру оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләре үткәрү нәтиҗәләре буенча исәпләр реестрлары өчен түләү Диспетчерлык үзәге тарафыннан, хисап аеннан соң килүче айның 20 сеннән дә соңга калмыйча, бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүмат, эшләр башкару (хезмәт күрсәтүләр) өчен исәп нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган медицина тикшерүләрен үткәрүгә норматив чыгымнар чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган 2014 елда Татарстан Республикасының балалар савыктыру учреждениеләре хезмәткәрләре тарафыннан алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина тикшерүләрен үтү өчен медицина учреждениеләре исемлеге үз көчен югалткан дип санарга.

2. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин